СОВЕТ УТЯШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Центральная, д.10,
с. Татарское Утяшкино,423186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ӘДӘМСӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Үзәк урамы, 10
Әдәмсә авылы,423186

тел.: (8-84348) 3-47-41, факс: (8-84348) 3-47-65, Ut.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Әдәмсә авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

2024 елның 26 ноябрьдан №48-173

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 19, 86-88 статьялары, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге Советы нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге Советының 10.03.2015 ел, №48-123 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына кертергә (Әдәмсә авыл җирлеге Советы карарлары редакциясендә: 12.10.2015 №3-9; 20.02.2016 №11-24; №20-43 24.11.2016; №27-58 19.04.2017; №37-75 15.12.2017; №43-91 22.05.2018; №49-106 14.12.2018; №55-123 8.07.2019; №67-149 15.06.2020; №13-36 31.05.2021, №18-62 28.12.2021; №24-84 12.07.2022; №32-118 17.03.2023; №42-159 12.04.2024;) (алга таба – Устав) түбәндәге үзгәрешләр:

1.1. Уставның 5 статьясындагы 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә: «21) «шәхси ярдәмче хуҗалык турында" 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

1.2. Уставның 41 статьясындагы 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 14 пункт өстәргә: «14) аның чит ил агенты статусын алуы»;

1.3. Уставның 50 статьясына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 өлешнең 3 пунктындагы икенче абзацын үз көчен югалткан дип таныргa;

1 өлешнең 7 пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыра, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру тора;»;

1 өлешнең 10 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

- «шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә ала.»;

1.4. Уставның 73 статьясына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 һәм 2 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Җирлек милкендә булырга мөмкин:

1) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

2) федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда җирлекнең җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук җирлекнең җирле үзидарә органнарының аларга 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешендә каралган тәртиптә тапшырылган аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт;

3) «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы»муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының норматив хокукый актлары нигезендә җирлек җирле үзидарә органнары һәм җирлек җирле үзидарәсе вазыйфаи затлары, җирлек муниципаль хезмәткәрләре, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәткәрләре эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

4) җирлекнең җирле үзидарә органнарына федераль законнар белән бирелгән һәм җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле мөлкәт, хәл итү хокукы;

5) 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 һәм 4 өлешләре, 16 статьясындагы 3 өлеше һәм 16.2 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләре нигезендә җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук 2003 елның 17 статьясындагы 1 һәм 1.1 өлешләре нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт 06.10.2003 №131-ФЗ.

2. Җирлекнең әлеге статьяның 1 өлеше таләпләренә туры килми торган мөлкәткә милек хокукы барлыкка килгән очракларда күрсәтелгән мөлкәт яңадан профильләштерелергә (мөлкәтнең максатчан билгеләнеше үзгәрергә) йә читләштерелергә тиеш. Мондый мөлкәтне читләштерү тәртибе һәм сроклары федераль закон белән билгеләнә.»;

3 өлешне үз көчен югалткан дип таныргa;

1.5. Уставның 74 статьясына түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарында билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда Муниципаль милектәге, система барлыкка китерүче территориаль челтәр оешмасына яисә Россия Федерациясе субъекты чикләрендә эш итүче территориаль челтәр оешмасына электр челтәре хуҗалыгы объектларын түләүсез биләүгә һәм файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыралар.».

2.Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда дәүләт теркәвенә алганнан соң түбәндәгеләрне бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль

берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https://novosheshminsk.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге Советының Законлылык, экология, Җирдән файдалану, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Әдәмсә авыл җирлеге башлыгы А.И. Назмутдинова